ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2024 с.Старое Дрожжаное № 433

2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,75 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыгарга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның "16" октябрь 433 номерлы карары белән расланган.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | жиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри-сиональ ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 83 699 | 95 607 | 122 722 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 44 232 | | 39 296 | 94 291 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 93 401 | 76 913 | 281 919 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 39 265 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 85 893 | 82 475 | 132 470 |
| Эстрада джаз сәнгате | авыл җирлеге | 129 245 | | 123 915 | | 203 145 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 66 606 | | 62 016 | 61 926 | 93 302 |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова